КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН ӨСКЕБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22 март 2019 № 5

Кукмара муниципаль район Түбән Өскебаш авыл Советының 2014нче елның 14нче мартында 10нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) йөкләмәләрен үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаны күчерү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2018нче елның 30нчы октябрендәге 387- ФЗ номерлы "Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законның 2нче һәм 28нче матдәләренә үзгәрешләр кертү хакындагы" Федераль закон белән тәңгәлләштерү максатыннан Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл Советы **карар итте:**

1.Кукмара муниципаль район Түбән Өскебаш авыл Советының 2014нче елның 14нче мартында 10нчы номерлы карары (2016нчы елның 12нче апрелендә 14нче номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) йөкләмәләрен үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаны күчерү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацында “хәлиткеч тавыш хокукы белән” сүзләрен “комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән” сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Түбән Өскебаш җирлеге башлыгы Н.М.Мөмәмәтҗанов